**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы № 89 « 30 » 03. 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Микулино авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (26.01.2015 №129, 09.09.2015 №148, 04.03.2016 №26 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законнарны үтәү йөзеннән

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 42 номерлы карары (2015 елның 26 гыйнварындагы 129 номерлы, 2015 елның 09 сентябрендәге 148 номерлы, 2016 елның 04 мартындагы 26 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Микулино авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге редакциядә үзгәреш кертергә:

"1.4.Халык тыңлауларына мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (Устава) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш, гамәлдәге Уставка әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 06.10.2003 N 131-ФЗ номерлы 13 статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар

җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча Микулино авыл җирлеге Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис: И.А.Такиулин